КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 26 ноябрь г.Казань № 1264

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы хөкүмәт комиссиясе турында» 2006 ел, 30 октябрь, 529 нчы карары белән расланган Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы хөкүмәт комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе турында» 2006 ел, 30 октябрь, 529 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 27 сентябрь, 513 нче; 2007 ел, 29 декабрь, 765 нче; 2008 ел, 14 май, 311 нче; 2008 ел, 5 декабрь, 866 нчы; 2009 ел, 24 апрель, 263 нче; 2010 ел, 19 гыйнвар, 18 нче; 2010 ел, 9 июнь, 458 нче; 2010 ел, 13 август, 656 нчы; 2010 ел, 6 декабрь, 1001 нче; 2011 ел, 10 май, 372 нче; 2012 ел, 4 апрель, 270 нче; 2012 ел, 1 июнь, 462 нче; 2012 ел, 20 октябрь, 877 нче; 2013 ел, 17 апрель, 259 нчы; 2013 ел, 7 октябрь, 731 нче; 2014 ел, 23 гыйнвар, 32 нче; 2015 ел, 3 март, 129 нчы; 2015 ел, 31 июль, 553 нче; 2016 ел, 10 декабрь, 915 нче, 2017 ел, 3 июнь, 334 нче һәм 2018 ел, 16 май, 370 нче; 2019 ел, 13 сентябрь, 823 нче; 2020 ел, 25 ноябрь, 1060 нчы; 2021 ел, 21 июль, 625 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы хөкүмәт комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составыннан А.Е.Борисовны, Е.Е.Воронинаны, Л.Р.Габдрахмановны, Л.Х.Гыйльметдиновны, Д.И.Фәттаховны, Р.Р.Хәйруллинны чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе башлыгы, комиссия рәисе урынбасары Рөстәм Рамил улы Гариповны (килешү буенча);

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсендәге юл инспекциясе һәм хәрәкәтне оештыру бүлегенең махсус йөкләмәләр буенча инспекторы, комиссия секретаре Фуад Фаил улы Исмаиловны (килешү буенча);

Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры Тимур Җәүдәт улы Сөләймановны;

Илназ Нуретдин улы Зиатдиновның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсендәге юл инспекциясе һәм хәрәкәтне оештыру бүлеге башлыгы (килешү буенча)»;

Радик Вахит улы Рамазановның вазифа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Транспорт өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Урта Идел төбәкара дәүләт автомобиль юлы күзәтчелеге идарәсе башлыгы – баш дәүләт инспекторы (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин